МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ

Федеральное государственное автономное образовательное учреждение высшего образования

«Казанский (Приволжский) федеральный университет»

УТВЕРЖДАЮ

Проректор по образовательной деятельности

__________ Д.А.Таюрский

«15» марта 2017г.

**ПРОГРАММА ВСТУПИТЕЛЬНОГО ИСПЫТАНИЯ**
**ПО СПЕЦИАЛЬНОСТИ**

для поступающих на программы подготовки научно-педагогических кадров в аспирантуре

**Направление 45.06.01 Языкознание и литературоведение**

*Направленность (профиль): 10.02.02 - Языки народов Российской Федерации (татарский язык)*

Казань 2017

Программа по татарскому языку предназначен для поступающих в аспирантуру по специальности 10.02.02 - Языки народов Российской Федерации (татарский язык). В программе представлены вопросы, выносимые на экзамен, основные требования, предъявляемые к поступающим в аспирантуру и критерии оценок.

## ТРЕБОВАНИЯ

к вступительным экзаменам в аспирантуру
по специальности 10.02.02 - Языки народов Российской Федерации (татарский язык)

Сдающие вступительный экзамен в аспирантуру по татарскому языку должны:

- знать теоретический материал по современному языкознанию;
- знать основные лингвистические школы и научные направления в татарском языкознании;
- владеть лингвистической терминологией, методами и приемами лингвистических исследований;
- обладать знаниями по истории развития татарского языка и по истории исследования татарского языкознания;
- рассматривать современный татарский язык в контексте проблем общего языкознания;
- уметь выявлять национальную специфику татарского языка, отраженную в языковых единицах;
- знать типологию татарского и других тюркских языков, языков, относящихся к алтайской семье, русского и европейских языков;
- обладать навыками лингвистического анализа текстов из художественной, научной, публицистической стилей и разговорной речи.

## Критерии оценок знаний и умений поступающих в аспирантуру по специальности 10.02.02 - Языки народов Российской Федерации (татарский язык)

«*Отлично*» - глубокое и всестороннее знание предмета, обязательной и дополнительной литературы, теоретического материала по основным разделам языкознания, важнейших лингвистических направлений и школ. Отличный ответ предполагает использование категориального аппарата при освещении лингвистических проблем; знание лингвистической терминологии, знание методов и приемов исследования строя татарского языка; проведение типологических параллелей между татарской и другими тюркскими, русским и отдельной европейской языками; умение аргументированно и логично излагать материал; владение методами и приемами лингвистического анализа.

«*Хорошо*» - знания в пределах Государственного образовательного стандарта при наличии отдельных пробелов; знакомство с обязательной и дополнительной литературой; аргументированное изложение материала; умелое применение теоретических знаний при лингвистическом анализе; владение необходимым объемом теоретического материала; доминирование традиционных взглядов на актуальные проблемы татарского языкознания, владение теоретическими понятиями, но недостаточное умение в их практическом применении; нарушения последовательности в ответе.

«*Удовлетворительно*» - знание предмета, обязательной литературы, недостаточное умение пользоваться теоретическим материалом при лингвистическом анализе, поверхностные и неполные ответы, соответствующие минимуму знаний, умений и навыков в области татарского языкознания.

«*Неудовлетворительно*» - методологические ошибки; отсутствие знаний основного содержания предмета; минимальные знания программы; отсутствие навыков лингвистического анализа; нелогическое изложение материала.

**Структура билета**.

Билет содержит три вопроса, предусматривающих проверку теоретических знаний и практических навыков. Первый вопрос предусматривает проверку знаний по общим проблемам языкознания, по основным теоретическим и методологическим проблемам тюркского и татарского языкознания, истории эволюции татарского языка, по истории татарского языкознания. Второй вопрос нацелен на проверку теоретических знаний по основным разделам татарского языкознания, по актуальным проблемам современного татарского языкознания. Третий вопрос содержит отрывок из литературного произведения и предусматривает проверку практических навыков применения теоретических знаний, выявления специфики функционирования в речи основных лексических и грамматических категорий.

*10.02.02 - Россия Федерациясе халыклары телләре (татар теле)* белгечлеге буенча аспирантурага кабул итү имтиханнарына

**ТАЛӘПЛӘР**

Татар теленнән аспирантурага керү имтиханы тапшыручылар түбәндәге белемнәргә ия булырга тиешләр:

- хәзерге тел белеме буенча теоретик материалны белергә;
- татар теле белемендәге төп лингвистик мәктәпләрне һәм фәнни юнәлешләрне белергә;
- лингвистик терминология, лингвистик эзләнү методлары һәм алымнары белән эшләү күнекмәләренә ия булырга;
- татар теленең үсешен һәм татар теле белеменең өйрәнелү тарихын белергә;
- хәзерге татар телен гомуми тел белеме проблемалары белән бәйләнештә күзаллый белергә;
- татар телен башка төрки телләр, алтай гомумилегенә караган телләр, рус һәм европа телләре белән типологик чагыштыра белергә;
- әдәби, фәнни, публицистик стильгә, сөйләм теленә һәм әдәби телгә караган текстларга лингвистик анализ ясау күнекмәләренә ия булырга тиешләр.

**10.02.02 - Россия Федерациясе халыклары телләре (татар теле) белгечлеге буенча аспирантурага керүчеләрнең белемнәрен һәм күнекмәләрен бәяләү КРИТЕРИЙЛАРЫ**

Татар теле фәненә караган төп һәм өстәмә әдәбиятны, тел белеменең төп тармаклары буенча теоретик мәгълүматларны, төп лингвистик мәктәпләр һәм юнәлешләрне тирәнтен һәм һәрьяклап үзләштергән очракта *"бик яхшы"* билгесе куела. *"Бик яхшы"* билгесенә лаек җавап лингвистик проблемаларны яктырткан категориаль аппаратны куллануны; лингвистик терминологияне белүне, татар теле төзелешен

өйрәнгәндә кулланылган метод һәм алымнарны белүне; татар телен башка төрки телләр, алтай гомумилегенә караган телләр, рус һәм европа телләре белән типологик чагыштыра белүне; җавапның логик эзлеклелектә һәм дәлилле булуын, лингвистик анализ методларын һәм алымнарын белеп, дөрес куллануны күзаллый.

Төп һәм өстәмә әдәбият белән таныш булган, татар тел белеменең актуаль мәсьәләләренә карашы традиционлыкка корылган, дәүләт белем бирү стандартлары кысаларында каралган материалны үзләштерүдә аерым төгәлсезлекләр булган, теоретик материалны гамәли яктан тиешенчә куллана белмәгән, җавап биргәндә эзлеклелек сакланмаган очракларда *"яхшы"* куела.

Предмет буенча бары тик төп әдәбиятны гына белгән, лингвистик анализда теоретик белемнәрне тиешенчә кулланмаган, җаваплар төпле һәм тулы булмаган, татар тел белеме буенча бары тик аз күләмле белем һәм күнекмәләргә ия булган очракларда *"канәгатьләнерлек"* билгесе куела.

Фәннең төп эчтәлеген белмәгән, методологик хаталар булган, программаны аз үзләштергән, лингвистик анализ күнекмәләре булмаган, материалны аңлатуда логик эзлеклелек сакланмаган очракларда *"канәгатьләнмәслек"* билгесе куела.

**Билет төзелеше**

Билетта имтихан тапшыручының теоретик һәм гамәли белем күнекмәләрен тикшерүгә юнәлгән өч сорау бирелә. Беренче сорау тел белеменең гомуми мәсьәләләренә, төрки һәм татар тел белеменең теоретик һәм методологик проблемаларына, татар теленең үсеш тарихына һәм татар тел белеме тарихына карый.

Икенче сорау татар теле белеменең төп тармаклары, актуаль мәсьәләләре буенча белемнәрне тикшерүгә юнәлгән.

Өченче бирем имтихан тапшыручының теоретик белемнәрен гамәлдә куллануын билгеләүгә юнәлгән.

***Вопросы для вступительных экзаменов***

**в аспирантуру** по специальности 10.02.02 - **Языки народов Российской Федерации (татарский язык)**

***10.02.02 - Россия Федерациясе халыклары телләре (татар теле) белгечлеге буенча аспирантурага керүчеләр өчен***

***сораулык***

1. Проблема классификации тюркских языков. Место татарского языка среди других тюркских языков. Отношение татарского языка к огузским и кипчакским группам тюркских языков. Периодизация истории татарского литературного языка / *Төрки телләрне төркемләү мәсьәләсе. Башка төрки телләр арасында татар теленең урыны. Татар теленең угыз һәм кыпчак төркемнәренә мөнәсәбәте. Татар әдәби теле тарихын чорларга бүлү.*
2. Характерные черты тюркских языков Урало-поволжского региона. Исследование истории татарского языка (труды Л.Заляй, М.Закиева, В.Хакова, Ф.Хисамовой, Ф.Юсупова, И.Башировой, Ф.Нуриевой и др.). / *Урал-Идел регионындагы төрки телләрнең үзенчәлекле билгеләре. Татар теле тарихын өйрәнү (Л.Җәләй, М.Зәкиев, В.Хаков, Ф.Хисамова, Ф.Йосыпов, И.Бәширова, Ф.Нуриева һ.б. хезмәтләре).*
3. Памятники тюркской письменности: руническое письмо, древнеуйгурское письмо, арабское письмо ./ *Төрки язма истәлекләр: рун язуы, борынгы уйгыр язуы, гарәп язуы.*
4. Письменные памятники Булгарского и Золотоордынского периодов и их отношение к современному татарскому языку. / *Болгар һәм Алтын Урда чоры язма истәлекләре, аларның хәзерге татар теленә мөнәсәбәте.*
5. Вопросы формирования и развития татарского языка. Различные взгляды на происхождение татарского литературного языка. Основные этапы развития татарского литературного языка. / *Татар теленең барлыкка килүе һәм үсеше. Татар әдәби теле барлыкка килүгә төрле карашлар. Татар әдәби теле үсешенең төп этаплары.*
6. Структурные и функциональные изменения в татарском языке. Роль экстралингвистических факторов в развитии татарского языка. / *Татар телендә структур һәм функциональ үзгәрешләр. Татар теле үсешендә экстралингвистик факторларның роле.*
7. Становление и развитие татарского языкознания. Дооктябрьский этап в истории татарского языкознания. Деятельность С.Хальфина, И.Гиганова, И.Хальфина, К.Насыйри, Г.Ибрагимова и др. / *Татар теле белеменең барлыкка килүе һәм үсеше. Татар тел белеме тарихында октябрьгә кадәрге чор. С.Хәлфин, И.Хәлфин, К.Насыйри, Г.Ибраһимов һ.б. эшчәнлеге*
8. Послеоктябрьский этап в истории татарского языкознания. Характеристика основных периодов. Деятельность Дж.Валиди, Г.Алпарова, Г.Шарафа, Л.Заляя, Ш.Рамазанова, М.З.Закиева, Д.Г.Тумашевой, В.Х.Хакова, Г.Ф.Саттарова, Ф.М. Хисамовой, Ю.Ф.Юсупова, Ф.С.Сафиуллиной и др. / *Татар тел белеме тарихында октябрьдән соңгы чор. Төп этапларны тасвирлау. Җ.Вәлиди, Г.Алпаров, Г.Шәрәф, Л.Җәләй, Ш.Рамазанов, М.Зәкиев, Д.Тумашева, В.Хаков, Г.Саттаров, Ф.Хисамова, Ф.Йосыпов, Ф.Сафиуллина һ.б. эшчәнлеге.*
9. Современное состояние татарского языкознания. Новые направления лингвистических исследований: ареальная лингвистика, лингвогеография,

социолингвистика, лингвокультурология, этнолингвистика, лингвофольклористика и др./ *Татар тел белеменең бүгенге торышы. Яңа лингвистик юнәлешләр: ареал лингвистика, лингвогеография, социолингвистика, лингвокультурология, этнолингвистика, лингвофольклористика һ.б.*

10. Язык как общественное явление. Основные функции языка. / *Иҗтимагый күренеш буларак тел. Телнең төп функцияләре.*

11. Язык и речь. Роль языка в процессе коммуникации. Массовая коммуникация. Строение текстов массовой коммуникации. Виды продукции массовой коммуникации. / *Тел һәм сөйләм. Сөйләшү, аралашу процессында телнең роле. Массакүләм аралашу. Массакүләм аралашу текстларының төзелеше. Массакүләм аралашу чараларының төрләре.*

12. Устная и письменная речь. Алфавиты и письменность тюркских языков. Проблемы совершенствования и реформирования графики и орфографии татарского языка. / *Язма тел һәм сөйләмә тел. Төрки телләрнең алфавитлары һәм язулары. Татар теленең графикасын һәм орфографиясен камилләштерү проблемалары.*

13. Язык и мышление. План выражения и план содержания языкового знака. Синтагматико-парадигматические отношения в языке. Знаковый характер языка. Понятие знака в философии, семиотике и лингвистике. Субстанциональное и функциональное значение языкового знака. / *Тел һәм фикерләү. Тел билгесенең эчтәлеге һәм белдерелүе. Телдә синтагматик, парадигматик мөнәсәбәтләр. Телнең билге (знак) булуы. “Билге” төшенчәсенең фәлсәфәдә, семиотикада һәм лингвистикада эчтәлеге. Тел билгесенең субстанциональ (тик торгандагы) һәм функциональ (хәрәкәттәге) мәгънәсе.*

14. Методы изучения языка: описательный, сравнительно-исторический, сопоставительный, метод компонентного анализа, социолингвистические, экспериментальные методы. *Телне өйрәнү методлары: тасвирлама, чагыштырма-тарихи, чагыштырма компонентлы анализ методы, социолингвистик һәм эксперименталь методлар.*

15. Грамматические, лексические, орфоэпические, орфографические, стилистические, логические, риторические, поэтические нормы татарского литературного языка. Ошибка и погрешность, творческое использование норм и сознательное отклонение от нормы в современном татарском языке. / *Татар әдәби теленең грамматик, лексик, орфоэпик, орфографик, стилистик, логик, риторик, поэтик нормалары. Тел нормалары сакланышындагы хаталар һәм төгәлсезлекләр; тел нормаларын иҗади куллану һәм хәзерге татар телендә нормадан махсус рәвештә читкә китү.*

16. Языковая система, ее функционирование и развитие. Элементы и структура языковой системы. Синхрония и диахрония. / *Тел системасы, аның кулланылышы һәм үсеше. Тел системасының элементлары һәм структурасы. Синхрония һәм диахрония.*

17. Ярусы (уровни) системы языка: уровнеобразующие и неуровнеобразующие единицы языка. / *Тел системасының катламнары, аларның төрләре.*

18. Предмет фонетики, ее разделы. Строение речевого аппарата и теории голосообразования. Фонетические сегментные и суперсегментные единицы. Звук и фонема. Дифференциальные признаки фонемы. Виды вариативности фонем. Состав фонем в татарском языке./ *Фонетика, аның бүлекләре. Сөйләм аппаратының төзелеше. Тавыш барлыкка килү теорияләре. Фонетик сегмент һәм суперсегмент элементлары. Аваз һәм фонема. Фонеманың аермалы билгеләре. Фонема вариантлылыгының төрләре. Татар телендә фонемалар составы.*

19. История изучения фонетики татарского языка (труды И.Гиганова, И.Хальфина, А.Троянского, К.Насыйри, Х.Максуди, Дж. Валиди, Р.Шакировой, Г.Ф.Саттарова, А. Афлетунова, Ф.М. Хисамовой, Х.Х.Салимова, Ф.Ю. Юсупова и др.) / *Татар теле фонетикасының өйрәнелү тарихы (И.Гиганов, И.Хәлфин, А.Троянский, К.Насыйри, Х.Максуди, Җ.Вәлиди, Р.Шакирова, Г.Саттаров, Ә.Әфләтунов, Ф.Хисамова, Х.Сәлимов, Ф.Йосыпов һ.б. хезмәтләре).*

20. Экспериментальное изучение татарской фонетики (деятельность В.А.Богородицкого, Г. Шарафа, У. Байчуры, Х.Х.Салимова, Т. Ибрагимова, Г.М. Сунгатова и др.). / *Татар фонетикасын эксперименталь өйрәнү ( В.Богородцкий, Г.Шәрәф, У.Байчура, Х.Сәлимов, Г.Ибраһимов, Г.Сөнгатов һ.б.)*

21. Вокализм татарского языка, принципы классификации гласных фонем. Разные взгляды на эту проблему (К.Насыйри, Г.Алпаров, У.Байчура, Х.Салимов и др.). Закон сингармонизма. Редукция гласных. Соотношения гласных татарского литературного языка и диалектов. Фонетические особенности различных языков Поволжья и Приуралья. Передвижение башкирско-татарских гласных./ *Татар теле вокализмы, сузык фонемаларны төркемләү принциплары, әлеге мәсьәләгә төрлечә карашлар (К.Насыйри, Г.Алпаров, У.Байчура, Х.Сәлимов, Т.Ибраһимов, Г.Сөнгатов һ.б. эшчәнлеге). Сингармонизм законы. Сузыклар кыскару. Татар әдәби телендә һәм диалектларда сузык авазлар. Идел буе һәм Урал телләрендә фонетик үзенчәлекләр. Татар башкорт телләрендә сузыклар күчеше.*

22. Консонантизм татарского языка. Фонетическая природа заимствованных согласных. Фонетические изменения в области согласных фонем. Соотношения согласных татарского литературного языка и диалектов. / *Татар теле консонантизмы. Алынма тартыкларның фонетик табигате. Сузык фонемалар өлкәсендәге фонетик үзгәрешләр. Татар әдәби телендә һәм диалектларда тартык авазларның туры килүе.*

23. Просодика современного татарского языка. Элементы просодики. Природа ударения и проблема словесного ударения в современном татарском языке. Структура и типы слогов. Интонация и интонационные конструкции./ *Хәзерге татар теле просодикасы. Просодик элементлар. Хәзерге татар телендә басымның табигате һәм сүз басымы проблемасы. Иҗек төзелеше һәм типлары. Интонация һәм интонациональ конструкцияләр.*

24. Лексикология татарского языка и ее разделы. Объект исследования и задачи лексикологии. Особенности лексической системы татарского языка. Тенденции развития лексики и фразеологии современного татарского литературного языка./ *Хәзерге татар теле лексикологиясе һәм аның тармаклары. Лексикологиянең өйрәнү объекты һәм бурычлары. Татар теле лексик системасының үзенчәлекләре. Хәзерге татар әдәби теле лексикасы һәм фразеологиясенең үсеш тенденцияләре.*

25. Слово как единица словарного состава языка. Слово и понятие. Семантический аспект слова. Лексическое значение слова, типы лексического значения. Многозначность слова. Иерархия значений и типы многозначности в татарском языке. Полисемия в толковых словарях татарского языка. / *Сүзлек составының төп берәмлеге буларак сүз. Сүз һәм төшенчә. Сүзнең семантик ягы. Сүзнең лексик мәгънәсе, лексик мәгънә типлары. Сүзнең күпмәгънәлелеге. Күпмәгънәлелек типлары һәм мәгънә иерархиясе.*

26. Явление лексической омонимии и антонимии в татарском языке. Типы омонимов и антонимов и их стилистические особенности. Синонимия как выражение смысловой эквивалентности в татарском языке. Типы синонимов. Синонимический ряд и его

доминанта./ *Татар телендә лексик антонимия һәм омонимия күренешләре. Антоним һәм омонимнарның типлары һәм стилистик үзенчәлекләре. Мәгънәви төрлелекне белдерүдә синонимнарның роле. Синонимнарның типлары. Синонимик рәт һәм доминанта сүз.*

27. Лексический состав современного татарского языка с точки зрения его происхождения и исторического формирования. Общеалтайский и древнетюркский период в развитии лексики кипчакских языков. Общетюркская лексика. / *Барлыкка килүе һәм формалашуы ягыннан хәзерге татар теленең лексик составы. Кыпчак телләренең үсешендә гомумалтай һәм борынгы төрки чор. Гомумтөрки лексика.*

28. Заимствованная лексика в татарском языке. Виды заимствований и их генетическая принадлежность. Особенности функционирования заимствованной лексики в современном татарском языке. / *Татар телендә алынма лексика. Алынмаларның төрләре һәм чыганаклары. Хәзерге татар телендә алынма лексиканың кулланылыш үзенчәлекләре.*

29. Социально-функциональная и экспрессивно-стилистическая характеристика лексики татарского языка. Общеупотребительная лексика, диалектизмы, терминологическая и профессиональная лексика, жаргоны и арго. Активный и пассивный состав лексики. Устаревшие слова и их типы. Неологизмы и их типы. / *Татар теле лексикасын иҗтимагый-функциональ һәм экспрессив-стилистик яктан төркемләү. Гомумкулланылыш лексикасы, диалекталь лексика, жаргон һәм арго лексика. Актив һәм пассив лексика. Искергән сүзләр, аларның типлары. Неологизмнар, аларның типлары.*

30. Ономастическая лексика. Специфика собственного имени в словарном составе языка. Основные разделы ономастики и степень их изученности в современном татарском языке (труды Г.Ф.Саттарова, М.З.Закиева, Ф.Г.Гариповой, Г.Р.Галиуллиной, Г.К.Хадиевой и др.). / *Ономастик лексика. Ялгызлык исемнәренең үзенчәлекләре. Ономастика фәненең төп тармаклары һәм хәзерге татар телендә һәм аларны өйрәнү дәрәҗәсе (Г.Саттаров, М.Зәкиев, Ф.Гарипова, Г.Галиуллина, Г.Хадиева һ.б. хезмәтләре).*

31. Фразеология татарского языка. Определение состава и принципы классификации. Деятельность Г.Ахунзянова, Н.Исанбет, Г.Ахатова, Р.А.Юсупова, Ф.С.Сафиуллиной и др. в развитии татарской фразеологии./ *Татар фразеологиясе. Аның составын билгеләү һәм фразеологизмнарны төркемләү принциплары. Г.Ахунҗанов, Н.Исәнбәт, Г.Әхәтов, Р.Юсупов, Г.Саттаров, Ф.Сафиуллина һ.б. татар фразеологиясенә керткән өлешләре.*

32. Формирование и развитие татарской лексикографии. Типы словарей. / *Татар лексикографиясенең барлыкка килүе һәм үсеше. Сүзлекләрнең типлары.*

33. История изучения словообразования в тюркологии и татарском языкознании. Формирование и развитие татарского словообразования. / *Төрки һәм татар тел белемендә сүз ясалышының өйрәнелү тарихы. Татар сүз ясалышы фәненең барлыкка килүе һәм үсеше.*

34. Морфемная структура слова в татарском языке. Типы морфем и их особенности. Понятие о нулевой морфеме. Историческое развитие аффиксов. Проблема классификации морфем в татарском языке (В.Н. Хангильдин, Д.Г. Тумашева, М.З.Закиев, Ф.А.Ганиев). / *Татар телендә сүзнең морфемик төзелеше. Морфема типлары һәм аларның үзенчәлекләре. Нуль морфема. Аффиксларның тарихи үсеше. Татар телендә морфемаларны төркемләү проблемалары (В.Хангильдин, Д.Тумашева, М.Зәкиев, Ф.Ганиев).*

35. Основные понятия словообразования: словообразовательная структура слова, словообразовательное значение. Словообразовательные типы модели. Словообразовательное гнездо и цель. / *Сүз ясалышының төп төшенчәләре: сүз ясалыш*

*структурасы, сүз ясалыш мәгънәсе. Сүз ясалыш тибы, моделе. Сүз ясалыш оясы һәм чылбыры.*

36. Способы словообразования в татарском языке. Различные взгляды на природу образования сложных слов (А.А.Юлдашев, Ф.А.Ганиев и др.). / *Татар телендә сүз ясалыш ысуллары. Кушма сүзләр ясалышына бәйле төрле карашлар ( А.Юлдашев, Ф.Ганиев һ.б.)*

37. Понятие о грамматическом строе татарского языка. Морфология как раздел языкознания, ее предмет, задачи, аспекты. Система частей речи в татарском языке. Проблема частей речи в татарском языкознании. / *Татар теленең грамматик төзелеше турында мәгълүмат. Тел белеменең бер тармагы буларак морфология, аның өйрәнү предметы, бурычлары һәм юнәлешләре. Татар телендә сүз төркемнәре системасы. Татар тел белемендә сүзләрне төркемләү проблемалары.*

38. Учение о грамматической категории. Грамматическое значение и средства его выражения. Взаимодействие лексического и грамматического значения в слове. Парадигматическое и синтагматическое значение грамматических форм. / *Грамматик категория турында өйрәтмә. Грамматик мәгънә һәм аны белдерү юллары. Сүздә лексик һәм грамматик мәгънәләрнең мөнәсәбәте. Грамматик формаларның парадигматик һәм синтагматик мәгънәләре.*

39. Имя существительное и его грамматические категории: число, падеж, принадлежность./ *Исем сүз төркеме һәм аның грамматик категорияләре: сан, килеш, тартым.*

40. Именные части речи: прилагательные, местоимения и числительные. Их разряды и основные функции в речи. / *Исем сүз төркемнәре: сыйфат, алмашлык һәм сан. Аларның төркемчәләре һәм сөйләмдәге төп функцияләре.*

41. Наречие, его разряды. Образование, связь с другими частями речи./ *Рәвеш һәм аның төркемчәләре. Ясалышы, башка сүз төркемнәре белән мөнәсәбәте.*

42. Глагол и его грамматические категории. / *Фигыль һәм аның грамматик категорияләре.*

43. Личные формы глагола и их парадигматическая и синтагматическая характеристика. Категория лица, залога, утверждение и отрицание. Способы глагольного действия. / *Затланышлы фигыль формалары һәм аларга парадигматик, синтагматик характеристика. Зат, юнәлеш, барлык һәм юклык грамматик категорияләре. Дәрәҗә белдерү юллары.*

44. Неличные формы глагола. Причастия, деепричастия, имена действия и инфинитив, их формы и функции. / *Затланышсыз фигыль формалары. Сыйфат фигыль, хәл фигыль, исем фигыль, инфинитив, аларның формалары һәм сөйләмдәге функцияләре.*

45. Глагольные формы и конструкции, выражающие модальные значения желательности, необходимости, возможности-невозможности, долженствования, намерения. Основные формы, на базе которых оформляют данные значения. Их отношение к категории времени, наклонения и лица. Перифрастические формы татарского глагола. / *Теләк, кирәклек, мөмкинлек һәм мөмкин түгеллек, тиешлек, ният, модаль мәгънәләрне белдерә торган фигыль формалары һәм конструкцияләре. Аларны төзүдә катнашкан формалар. Бу формаларның заман, наклонение һәм зат категорияләренә мөнәсәбәте. Татар телендә тасвирлама фигыль формалары.*

46. Вспомогательные части речи. Взаимодействие их между собой и с другими частями речи. Активизация старых и образование новых вспомогательных средств языка.

Междометия. Звукоподражания. Модальные слова. / *Ярдәмлек сүз төркемнәре. Аларның үзара һәм башка сүз төркемнәре белән мөнәсәбәте. Хәзерге татар телендә ярдәмлек сүзләрнең һәм чараларның искергән формалары активлашу һәм яңа төрләре барлыкка килү.*

47. Синтаксис как наука о системе строения речи. Основные направления в синтаксисе. Предложение как основная синтаксическая единица речи. Основные признаки: предикативность и модальность. Принципы классификации предложений в татарском языкознании. / *Сөйләм төзелешен өйрәнә торган фән буларак синтаксис. Синтаксис фәнендә төп юнәлешләр. Сөйләмнең төп синтаксик берәмлеге буларак җөмлә, аның төп үзенчәлекләре: хәбәрлек һәм модальлек. Татар тел белемендә җөмләләрне төркемләү принциплары.*

48. Связь слов в речи. Сочинительная и подчинительная связь между словами. Традиционные типы связи слов: согласование, примыкание, управление. Взгляды татарских языковедов по этому вопросу (А.Казембек, В.Хангильдин, И.Низамов, Ф.Сафиуллина)./ *Сөйләмдә сүзләр бәйләнеше. Сүзләр арасында тезүле һәм иярүле бәйләнешләр. Иярүле бәйләнешнең традицион бүленеше: ярашу, башкарылу, янәшәлек. Бу мәсьәләгә татар тел белгечләренең карашлары (А.Казембек, В.Хангильдин, И.Низамов, Ф.Сафиуллина).*

49. Словосочетание и его типы. / *Сүзтезмә, аның төрләре.*

50. Традиционное грамматическое членение предложения на главные и второстепенные члены. Актуальное членение предложения. Синтагматическое членение предложения. Соотношение и взаимосвязь между этими членениями. / *Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләргә бүленеше. Җөмләнең актуаль һәм синтагматик кисәкләре, аларның үзара мөнәсәбәте. Җөмләнең синтагматик кисәкләре, аларның үзара мөнәсәбәте һәм бәйләнеше.*

51. Главные члены предложения. Связь между ними. Подлежащее, сказуемое и их семантика. Типы именного и глагольного сказуемого. / *Җөмләнең баш кисәкләре, аларның үзара бәйләнеше. Ия, хәбәр, аларның мәгънәсе. Исем хәбәр һәм фигыль хәбәр төрләре.*

52. Второстепенные члены предложения. Принципы их классификации. Трудности в определении второстепенных членов предложения./ *Җөмләнең иярчен кисәкләре. Аларны төркемләү принциплары. Иярчен кисәкләрне билгеләүдәге кыенлыклар.*

53. Синтагматическое членение татарской речи. Обособленные члены предложения. Актуальное членение предложения и порядок слов в предложении. Стилистические функции порядка слов в татарском языке. / *Сөйләмнең синтагматик бүленеше. Аерымланган җөмлә кисәкләре. Җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленеше. Җөмләдә сүз тәртибе. Татар телендә сүз тәртибенең стилистик функциясе.*

54. Простые предложения и их разновидности. / *Гади җөмлә, аның төрләре.*

55. Сложные предложения и их классификация. Типы и структура сложных предложений. Сложносочиненные предложения./ *Кушма җөмлә, аларны төркемләү принциплары. Кушма җөмләләрне бәйләнеш төреннән, төзелешеннән чыгып төркемләү. Тезмә кушма җөмлә.*

56. Семантическая и функциональная классификация сложноподчиненных предложений в татарском языкознании. Их синтетические и аналитические типы. / *Татар тел белемендә иярченле кушма җөмләләрне мәгънәви һәм функциональ яктан төркемләү. Иярченле кушма җөмләнең аналитик һәм синтетик төрләре.*

57. Структура сложного многокомпонентного предложения. Учение о синтаксическом целом./ *Катлаулы кушма җөмлә төзелеше. Синтаксик бөтен турында өйрәтмә.*

58. Синтаксис разговорной речи и конструкции, характеризующие ее. Структурно-грамматические особенности монологической и диалогической речи. / *Сөйләм синтаксисы һәм аны билгели торган конструкцияләр. Монологик һәм диалогоик сөйләмнең структур-грамматик үзенчәлекләре.*

59. Синтаксис текста. Целостность текста, семантика и синтактика текста. Разновидности текста. / *Текст синтаксисы. Текст бөтенлеге, сематикасы һәм синтактикасы.*

60. Основы татарской пунктуации. Пунктуация и интонация./ *Татар пунктуациясенең нигезләре. Пунктуация һәм интонация.*

**Основная литература**


1. Ахметьянов Р.Г. Общая лексика материальной культуры народов Среднего Поволжья. – М., 1989.
2. Галиуллина Г.Р. Татар теле. Лексикология: таблицалар, схемалар, анализ үрнәкләре, күнегүләр, сүзлекчә: Югары сыйныф укучылары һәм студентлар өчен / Г.Р.Галиуллина. – Казан: Мәгариф, 2007.
3. Галиуллина Г.Р. Хәзерге татар теле лексикологиясе: укыту кулланмасы. – Казан: Казан ун-ты, 2013.
4. Ганиев Ф.А. Функциональное словообразование в современном татарском литературном языке. – Казань, 2009.
5. Ганиев Ф.Ә. Хәзерге татар әдәби теле. Сүзьясалышы. (Югары уку йорты студентлары өчен). – Казан: Мәгариф, 2000.
6. Әхәтов Г. Х. Татар теленең лексикасы. –Казан, 1995.
7. Закиев М.З. Татар синтаксисы. – Казан: Татар кит. нәшр., 2008.
8. Замалетдинов Р.Р. Теоретические и прикладные аспекты татарской лингвокультурологии. – Казань: Магариф, 2009.
9. Нуриева Ф.Ш. Исторические и лингвистические условия формирования тюрко-татарского литературного языка периода Золотой Орды. – Казань, 2004.
10. Проблемы лексикологии и лексикографии татарского языка. – Казань, 2003.
11. Рамазанова Д.Б. Вопросы татарской диалектологии. – Казань: ИЯЛИ АН РТ, 2008.
12. Салимова Д.А. Части речи: история изучения и вопроса классификации. Учебное пособие. – Казань: РИЦ «Школа», 2004
13. Саттаров Г.Ф. Татар топонимиясе. – Казан, 1998.
14. Сафиуллина Ф. С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. - Казан, 1999.
15. Сафиуллина Ф.С. Синтаксис татарской разговорной речи. - Казань, Из-дво КГУ, 1979.
16. Сәлимов Х.Х. Татар теле фонетикасы. – Чаллы: КамАЗ нәшр, 1993.
17. Татар грамматикасы. III томда. / Ред. Колл. М.З. Зәкиев, Ф.Ә. Ганиев, К.З. Зиннатуллина. – М.: Инсан; Казан: Фикер, 1998-2002.
18. Татар халык сөйләшләре: 2 кит. / [авторлар коллективы: Ф. С. Баязитова, Д. Б. Рамазанова, Т. Х. Хәйретдинова һ. б.; редкол.: К. М. Миңнуллин һ. б.; җав. ред.: Д. Б. Рамазанова, Т. Х. Хәйретдинова].—Казан: Мәгариф, 2008.
19. Тумашева Д.Г. Татарский глагол (опыт функционально-семантического исследования грамматических категорий). – Казань, 1986.
20. Тумашева Д.Г. Хәзерге татар әдәби теле. Морфология. Югары уку йорты студентлары өчен дәреслек-кулланма. – Казан, 1978.

21. Хадиева Г.К. Хәзерге татар әдәби теле фонетикасы: Уку-укыту кулланмасы.- Казан: Казан. ун-ты, 2012.
22. Хайруллин М.Б. Развитие разносистемных языков в контексте интеграции в общеевропейскую культуру. – Казань: Изд-во КГУ, 2008.
23. Хаков В.Х. татар әдәби теле тарихы. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993.
24. Хаков В.Х. Тел – тарих көзгесе (татар әдәби теле үсеше тарихыннан). – Казан: Татар кит. нәшр., 2003.
25. Хәкимҗан Ф. Татар әдәби теле: Фонетика. Югары уку йортлары студентлары өчен. – Тулылан. 2 нче басма. – Казан: ТДГИ, 2001.
26. Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе. – Казан: Мәгариф, 2006.
27. Юсупов Ф.Ю. Изучение татарского глагола. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1986.
28. Юсупов Ф.Ю. Морфология татарского диалектного языка. – Казань: Фән, 2004.
29. Юсупова А.Ш. Двуязычная лексикография татарского языка XIX века. - Казань: Изд-во Казан. гос. ун-та, 2008.


**Дополнительная литература**


1. Актуальные вопросы татарского языкознания / Акад. наук Респ. Татарстан, Ин-т яз., лит. и искусства им. Г. Ибрагимова; [редкол.: М. З. Закиев (отв. ред.), З. А. Исхакова (сост.)].—Казань: ИЯЛИ АН РТ, 2007.
2. Алпаров Г. Сайланма хезмәтләр (Татар грамматикасы һәм гомуми тел белеме мәсьәләләре. – 1945.
3. Ахунҗанов Г. Х. Татар теленең идиомалары. – Казан, 1972.
4. Ахунзянов Э. М. Русские заимствования в татарском языке. – Казань, 1968.
5. Әхмәтьянов Р. Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. – Казан, 2001.
6. Баскаков Н.А. Татарский язык. (Тюркские языки). – М., 1960.
7. Богородицкий В.А. Введение в татарское языкознание. – Казань, 1953.
8. Вәлиуллина З.М., Зиннәтуллина К.З., Сәгыйтов М.Л. Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе. – Казан, 1972.
9. Галиуллина Г.Р. Татарские личные имена в контексте лингвокультурных традиций.- Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2008.
10. Ганиев Ф.А. Видовая характеристика татарского глагола. – К., 1963.
11. Гиганов И. Грамматика татарского языка. – СПб., 1801.
12. Дмитриев Н.К. Грамматика башкирского языка. – М. – Л., 1948.
13. Җамалетдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният: татар лингвокультурологиясе нигезләре / Р.Р. Җамалетдинов. – Казан: Мәгариф, 2006.
14. Закиев М.З. История татарского народа (Этнические корни, формирование и развитие). – М.: Инсан, 2008.
15. Зиннатуллина К.З. Залоги глагола в современном татарском литературном языке. – Казань, 1969.
16. Ибраһимов Г. Татар сарыфы. – Казан, 2003.
17. Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков: в 3т. – М., 1956.
18. Мәхмүтов М.И. Татар әдәби теленә кергән гарәп-фарсы элементлары // Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. — Казан, 1993, II том.
19. Низамов И.М. Татар социолингвистикасы.—Казан: Казан дәүләт ун-ты, 2006.
20. Рәхимова Р. К. Татар теленең һөнәрчелек лексикасы.-Казан, 1983.
21. Саттаров Г. Ф. Татар антропонимикасы. –Казан, 1990.
22. Серебренников Б.А. Система времен татарского глагола. – Казань, 1963.
23. Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Пратюркский язык-основа. Картина мира пратюркского этноса по данным языка. М.: Наука, 2006.
24. Фасеев Ф. С. Татар телендә терминология. –Казан, 1970.

25. Хайруллин М. Б. Проблемы развития лексической системы татарского литературного языка. –Казань, 2000.
26. Ханбикова Ш. С., Сафиуллина Ф. С. Синонимнар сүзлеге.— Казань, 1999.
27. Хангилдин В.Н. Татар теле грамматикасы. – К., 1959.
28. Юсупов Ф.Ю. Изучение татарского глагола. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1986.
29. Юсупов Ф.Ю. Татар теленең диалектлары. Урал сөйләшләре. – Казан: Татар кит. нәшр., 2003.